**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-236 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы Указының 9 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты структурасына һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы Указының 6 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 13 пункты.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 30 май
№ 360

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «_30_» _маендагы_
_360_ номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты (алга таба шулай ук – секретариат) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

2. Секретариат Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе эшчәнлеген оештыру ягыннан, хокукый, аналитик, документлар белән һәм башкача тәэмин итү максатларында төзелде.

3. Секретариат Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан төзелә, үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе җитәкчелегендә башкара, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенә, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

4. Секретариат үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

5. Секретариат турында нигезләмә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

II. Секретариатның төп максаты, бурычлары
һәм функцияләре

6. Секретариатның төп максаты булып «Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе турында» 2010 елның 30 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең үзенең төп бурычларын, хокукларын һәм йөкләмәләрен гамәлгә ашыруын тәэмин итү тора.

7. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе эшчәнлеген тәэмин итү максатларында секретариат түбәндәге төп бурычларны һәм вазыйфаларны тормышка ашыра:

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе кушуы буенча республикада социаль-икътисадый, иҗтимагый-сәяси вазгыять турында мәгълүмат җыюны, эшкәртүне һәм анализлауны оештыра, аналитик докладлар, мәгълүмат, белешмәләр, башка материаллар һәм документлар әзерли;

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе уздыра торган чараларны, очрашуларны, эш сәфәрләрен, аның катнашындагы сөйләшүләрне планлаштыра, координацияли, әзерли һәм уздыруны тәэмин итә, кирәк булганда аларны оештыру-техник яктан тәэмин итүне тормышка ашыра;

эшчәнлегендә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе катнашкан фондлар һәм коммерциячел булмаган башка оешмалар эшчәнлеген мәгълүмати яктан тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча башка бурычлар һәм функцияләр үти.

## III. Секретариатның хокуклары

8. Үз бурычларын һәм функцияләрен тормышка ашыру өчен секретариат түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалар һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материалларны соратып алырга;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карала торган Татарстан Республикасы закон чыгару актлары проектларын эшләүдә катнашырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системаларындагы мәгълүматлардан файдаланырга;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт элемтә һәм коммуникация системаларыннан файдаланырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килештереп, Россия Федерациясе законнары нигезендә аерым эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен фән һәм мәгариф оешмаларын, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә.

## IV. Секретариатның хезмәттәшлек итү даирәсе

9. Секретариат үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм вазыйфаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## V. Җаваплылык

10. Секретариат хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

## V. Секретариат эшчәнлеген оештыру

11. Секретариатның структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

12. Секретариат эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе белән килештереп, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе (алга таба – секретариат җитәкчесе) җитәкчелек итә.

13. Секретариат җитәкчесе:

секретариат эшен оештыра, секретариатка йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була;

секретариатның төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

үз компетенцияләре чикләрендә документларга кул куя һәм имза сала;

секретариат хезмәткәрләре арасында хезмәт бурычларын бүлә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә аларның вазыйфаи регламентларын раслауга тапшыра;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә секретариатның структурасы, штат саны, секретариат хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую һәм биләгән вазыйфасыннан азат итү турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә секретариат хезмәткәрләрен бүләкләү һәм аларны дисциплинар җәзага тарту турындагы тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән секретариат компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнаша;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары уздырган коллегия утырышларында, киңәшмәләрдә катнаша, секретариат вәкилләрен билгеләнгән тәртиптә коллегия утырышларында һәм киңәшмәләрдә катнашырга җибәрә.

14. Секретариат җитәкчесе вакытлыча эш урынында булмаганда, аның вазыйфаларын секретариатның вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

15. Секретариат хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе белән килештереп, секретариат җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.